ГЛАВА
БОЛЬШЕПОЛЯНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗУР ПОЛЯНКА АВЫЛ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**01.11.2021** Зур Полянка авылы **№ 1**

**«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Алексеевск муниципаль районының Зур Полянка авыл җирлегенең Александровка авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 56, 25.1 маддәсендәге 1 өлешенең 4, 4.1 һәм 4.3 пунктлары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Алексеевск муниципаль районының Зур Полянка авыл җирлеге Уставының 23 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советының 2019 елның 08 октябрендәге 105 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәнең 2.5 пункты нигезендә

**карар бирәм:**

1. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Полянка авыл җирлеге башлыгын билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Полянка авыл җирлегенең Александровка авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 12 ноябренә 10:00 сәгатькә билгеләргә.

Җыенны үткәрү урыны итеп түбәндәге адрес буенча урнашкан МФЦ бинасын билгеләргә: Татарстан Республикасы, Александровка авылы, Тыныч ур., 9А й.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Зур Полянка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда үзара салым кертүгә сез, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

- җирлек эчендәге юлларны карап тоту;
- җирлек эчендәге юлларны ремонтлау;
- торак пунктларда урамнарны яктыртуны карап тору.

ӘЙЕ   ЮК».

4. Әлеге карарны Зур Полянка авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы, Александровка авылы, Тыныч ур., 9А йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Полянка авыл җирлеге Александровка МФЦ бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Алексеевск муниципаль районының**
**Зур Полянка авыл җирлеге башлыгы** **М.Р. Афанасьева**